| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**20.01.2026** | Зеленодольск шәһәре | **КАРАР**<br>**83** |
|---|---|---|

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруга хокук сату буенча электрон аукционны оештыру һәм үткәрү турында нигезләмәне раслау хакында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы 1 өлешенең 10 пункты, Россия Федерациясенең Җир кодексының 39.33 статьясы 1 өлешенең 6 пункты, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законга, 2009 елның 28 декабрендәге «Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу нигезләре турында» 381-ФЗ номерлы Федераль законга, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль милектә булган җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә һәм җир кишәрлекләрендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 13 августындагы 553 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы белән, Зеленодольск муниципаль районының Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Әлеге карарның 1 нче кушымтасында каралганча, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруга хокук сату буенча электрон аукционны оештыру һәм үткәрү турында нигезләмәне расларга.
2. Әлеге карарның 2 нче кушымтасында каралганча, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру буенча сатуларны оештыру һәм уздыру комиссиясе составын төзергә һәм расларга.
3. Әлеге карарның 3, 4 нче кушымталарында каралганча, стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыруга шартнамәләрнең типлаштырылган формаларын расларга.
4. Әлеге карарның 5 нче кушымтасында каралганча, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге

территориясендә стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыру хокукының башлангыч (минималь) бәясен билгеләү методикасын расларга.

5. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыруга хокук сату буенча аукцион оештыру һәм уздыру турында нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 13 апрелендәге 806 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

6. Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге башлыгына әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми (http://pravo.tatarstan.ru) порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) сайтында урнаштырырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче З.Ф. Хәбибуллин

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2026 елның 20 гыйнварындагы
83 номерлы карарына
1 нче кушымта

.

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы«Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруга хокук сату буенча электрон аукцион оештыру һәм уздыру турында нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруга хокук сату буенча электрон аукцион оештыру һәм уздыру тәртибен билгели (алга таба - Нигезләмә).

1.2. Әлеге Нигезләмә 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы 1 өлешенең 10 пункты, Россия Федерациясенең Җир кодексының 39.33 статьясы 1 өлешенең 6 пункты, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законга, 2009 елның 28 декабрендәге «Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу нигезләре турында» 381-ФЗ номерлы Федераль законга, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль милектә булган җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә һәм җир кишәрлекләрендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 13 августындагы 553 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы белән эшләнгән.

1.3. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын (алга таба - НТО) урнаштыру хокукын сату буенча аукцион катнашучылар составы буенча ачык һәм электрон аукцион (алга таба - электрон аукцион) формасында үткәрелә.

1.4. Электрон аукционның предметы НТО урнаштыру хокукы (алга таба - лот) булып тора.

1.5. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Зеленодольск шәһәре муниципаль берәмлеге исеменнән электрон аукцион үткәрүне Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба - Вәкаләтле орган) электрон мәйданчыклар операторлары арасыннан Вәкаләтле орган тарафыннан сайланган һәм үзара хезмәттәшлек турында килешү төзелгән электрон мәйданчык операторы (алга таба - ЭМ операторы) белән берлектә башкара .

1.6. Электрон аукционны үткәрү Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге

территориясендә НТО урнаштыруга торглар оештыру һәм үткәрү буенча даими эшләүче комиссия (алга таба - Комиссия) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Комиссия биш кешедән тора һәм аны рәис җитәкли.

Комиссия составы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән раслана.

Комиссия утырышында әгъзаларының гомуми санынннан кимендә 50 проценты катнашса, комиссия үз функцияләрен башкарырга хокуклы.

## II. Төп терминнар

2.1. Автоматлаштырылган система (АС) - ЭМ операторының аппарат-программа комплексы.

2.2. Аккредитацияләү - мөрәҗәгать итүчегә оператор регламенты таләпләре нигезендә ЭМ операторының ябык өлешендә эшләү мөмкинлеген бирү.

Блоклау өчен субсчет - мөрәҗәгать итүченең электрон аукционда катнашуын тәэмин итү максатыннан, ЭМ операторы исәп-хисап счетына күчерелгән мөрәҗәгать итүченең акчаларын блоклау өчен файдаланыла торган мөрәҗәгать итүче субсчеты

2.4. Шартнамә - Россия Федерациясе Граждан кодексында, башка федераль законнарда һәм муниципаль хокукый актларда каралган тәртиптә Вәкаләтле орган белән сәүдә субъекты арасында электрон аукцион нәтиҗәләре буенча төзелгән НТО урнаштыру хокукын сату-алу шартнамәсе.

2.5.ЭМ операторы – Россия Федерациясе территориясендә билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә алынган оештыру-хокукый формасына, милек формасына, капиталның урнашу урынына һәм барлыкка килү урынына бәйсез формада сайлап алынган электрон мәйданчык, анда эшләү өчен кирәкле программа-аппарат чараларына ия булган һәм мондый мәйданчыкта электрон аукционнар үткәрүне тәэмин итүче юридик зат.

2.6. Вәкаләтле органның сайты - «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районы (http://zelenodolsk.tatarstan.ru)сайты (алга таба - Вәкаләтле органның сайты).

2.7. Электрон аукционда җиңүче – әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә НТО урнаштыру хокукы өчен иң зур хакын тәкъдим иткән зат;

2.8. Заявкаларның беренче өлешләрен карап тикшерү беркетмәсе - Комиссия әгъзалары тарафыннан имзаланган, мөрәҗәгать итүченең электрон аукционда катнашучы итеп танылуы һәм сессиягә кертелүе турында белешмәләрне үз эченә алган беркетмә.

2.9.Электрон аукцион үткәрү беркетмәсе - электрон аукцион буенча сессия уздырганнан соң ЭМ операторы тарафыннан төзелгән беркетмә.

2.10. Нәтиҗәләр чыгару беркетмәсе – катнашучыны электрон аукционда җиңүче итеп тануны һәм электрон аукцион нәтиҗәләре турында белешмәләрне үз эченә алган, Комиссия әгъзалары тарафыннан имзалана торган беркетмә.

2.11. Вәкаләтле орган счеты – Вәкаләтле органга күчерү өчен билгеләнгән, катнашучыларның акчаларын күчерү өчен Вәкаләтле орган электрон мәйданчыкта регистрация узганда ЭМ операторы тарафыннан теркәлә торган счет.

2.12. Мөрәҗәгать итүче- оештыру-хокукый формасына, милек формасына, капиталның урнашу урыны һәм барлыкка килү урынына бәйсез рәвештә индивидуаль эшкуар яки юридик зат яисә «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик зат.

2.13.Электрон аукционда катнашучы – электрон аукционда катнашуга заявка биргән һәм Комиссия карары белән электрон аукционда катнашучы дип танылган мөрәҗәгать итүче.

2.14. Электрон документ – мәгълүмат электрон-цифрлы формада, шул исәптән кәгазь документларның сканлаштырылган версияләрендә бирелгән документ.

2.15. Электрон цифрлы имза – электрон рәвештәге башка мәгълүматка (имзалана торган мәгълүматка) кушылган яисә мондый мәгълүматка башкача бәйле булган һәм мәгълүматны имзалаучы затны билгеләү өчен файдаланыла торган электрон рәвештәге мәгълүмат.

## III. Вәкаләтле орган вәкаләтләре

Вәкаләтле орган:

3.1. Әлеге карарның 5 нче кушымтасы каралганча НТО урнаштыруга хокукның башлангыч (минималь) бәясен билгеләү методикасы нигезендә бөтен чор эчендә НТО урнаштыру хокукының башлангыч (минималь) бәясен (алга таба - лотның башлангыч (минималь) бәясе) билгели.

3.2. Лотларның күләме һәм составын билгели.

3.3. Аукцион документациясен эшли һәм раслый.

3.4. Электрон аукционда катнашу өчен заявкаларны кабул итүнең башлану һәм тәмамлану даталарын, электрон аукцион үткәрү датасын билгели.

3.5. Заявка тәэмин итүнең срогы һәм шартларын билгели.

3.6. Электрон мәйданчыкта һәм Вәкаләтле орган сайтында электрон аукцион уздыру турында мәгълүмати хәбәр әзерләүне һәм бастырып чыгаруны оештыра.

3.7.Мөрәҗәгать итүчегә мөрәҗәгать иткән көннән алып ике эш көне эчендә аукцион документациясе нигезләмәләрен аңлату буенча рәсми мөрәҗәгать җибәрә.

3.8. Заявкаларны кабул итү тәмамлану датасына бер эш көненнән дә соңга калмыйча аукцион документациясенә үзгәрешләр кертү турында карар кабул итә. Аукцион документациясенә кертелгән үзгәрешләр электрон мәйданчыкта, Вәкаләтле орган сайтында урнаштырыла.

3.9. Тиешле мәгълүматны электрон мәйданчыкта, Вәкаләтле органның рәсми сайтында урнаштырып, электрон аукционны үткәрүне туктату турында теләсә кайсы вакытта, әмма аны үткәрү датасы башланырга өч көннән дә соңга калмыйча, карар кабул итә,

3.10. Электрон аукцион нәтиҗәләре турында мәгълүматны электрон мәйданчыкта, Вәкаләтле органның сайтында урнаштыра.

Электрон аукционда катнашучы буларак мөрәҗәгать итүче электрон мәйданчыкта, Вәкаләтле органның сайтында урнаштырылган аукцион документациясе белән, кертелгән үзгәрешләрне дә исәпкә алып, танышмаган очракта, Вәкаләтле орган җавап тотмый.

3.11.Электрон аукционны Россия Федерациясе законнары , «Россия Федерациясендә эшчәнлекне дәүләт тарафыннан җайга салу нигезләре турында» 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясындагы 4 өлеше нигезендә кертелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектлары арасында гына үткәрү таләбен билгели.

3.12.НТО урнаштыруга хокук сату-алу шартнамәсен төзи;.

3.13. НТО урнаштыруга хокук сату-алу шартнамәләре шартлары үтәлешен контрольдә тота

## IV. ЭМ операторы вәкаләтләре

ЭМ операторы:

4.1.Әлеге Нигезләмә нигезендә ЭМ операторы хезмәтләрен күрсәтә.

4.2. Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарында билгеләнгән тәртип нигезендә электрон мәйданчыкның эшкә яраклыгын һәм эшчәнлеген тәэмин итә. Электрон аукцион үткәрү өчен кулланыла торган программа һәм техник чараларның өзлексез эшләвен, ышанычлы эшләвен, аукционда катнашучыларның электрон аукцион тәмамлану вакытына бәйсез рәвештә анда катнашу мөмкинлеген тәэмин итә.

4.3. Электрон мәйданчыкта аккредитацияне раслаганнан соң, мөрәҗәгать итүчегә электрон аукционда катнашу мөмкинлеген тәэмин итә.

4.4.Вәкаләтле органга электрон аукционнар уздыру өчен шәхси кабинетка керү мөмкинлеген тәэмин итә.

4.5. Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары буенча электрон мәйданчыкта электрон документлардан файдалануны тәэмин итә.

4.6. Заявкаларны һәм аларга кушылып бирелгән документларны кабул итә.

4.7. Заявкаларны исәпкә ала һәм теркәп бара.

4.8. Катнашучыларга заявкаларына карата кабул ителгән карар турында хәбәр итә.

4.9. Электрон аукцион үткәрү беркетмәсен төзи.

4.10. Мөрәҗәгать итүчеләр, катнашучылар һәм электрон аукцион җиңүчесе белән заявка тәэминатын кабул итү һәм кире кайтару буенча исәп-хисаплар ясый.

4.11. Электрон мәйданчыкта техник җитешсезлекләр барлыкка килгән очракта, барлык мөрәҗәгать итүчеләргә, электрон аукционда катнашучыларга һәм Вәкаләтле органга мондый җитешсезлекләр турында, шулай ук яңа электрон аукцион датасы һәм вакыты турында хәбәр итә.

## V. Комиссиянең вәкаләтләре

Комиссия:

5.1. Заявкаларны һәм аларга кушылып бирелгән документларны карый.

5.2. Электрон аукционда катнашучылар- мөрәҗәгать итүчеләр дип тану яки мөрәҗәгать итүчеләрне электрон аукционда катнашырга рөхсәт итүне кире кагу турында карар кабул итә һәм заявкаларның беренче өлешләрен карап тикшерү беркетмәсен рәсмиләштерә.

5.3. Электрон аукцион җиңүчесен билгели.

5.4.Электрон аукцион нәтиҗәләрен чыгару беркетмәсен рәсмиләштерә.

## VI.Электрон аукционда катнашучыларга - мөрәҗәгать итүчеләргә карата таләпләр

6.1. Электрон аукционда катнашучы- мөрәҗәгать итүче булып электрон мәйданчыкта аккредитация узган индивидуаль эшкуар яисә капиталның оештыру-хокукый формасына, милек формасына, кайда урнашуына, шулай ук килеп чыгу урынына бәйсез рәвештә юридик зат яисә «һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик зат тора.

6.2. Электрон аукционда катнашучылар- мөрәҗәгать итүчеләр Россия Федерациясе законнары белән мондый катнашучыларга билгеләнгән таләпләргә туры килергә тиеш, шул исәптән түбәндәгеләр зарур :

6.2.1. юридик затның, индивидуаль эшкуарның ликвидация факты булмау һәм юридик затны, индивидуаль эшкуарны, "Һөнәри керемгә салым" махсус салым режимын кулланучы физик затны банкрот дип тану һәм конкурс производствосын ачу турында арбитраж суд карарлары булмау;

6.2.2. заявка биргән көнгә административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексында каралган тәртиптә эшчәнлекне туктатып тору факты булмау.

## VII. Электрон аукционда катнашу өчен заявканы тәэмин итү һәм электрон аукцион адымы

7.1. Электрон аукционда катнашуга заявка бирү өчен мөрәҗәгать итүче блок субсчетына акча күчерә:

7.1.1. заявканы тәэмин итү сыйфатында-лотның башлангыч (минималь) бәясенең 100 проценты күләмендә, әмма 50 (илле) мең сумнан да ким түгел. Электрон аукцион нәтиҗәләре буенча лотның йомгаклау бәясе 50 (илле) мең сумнан кимрәк булган очракта, Вәкаләтле орган җиңүченең реквизитларына акча аермасын ЭМ операторы акча күчергәннән соң биш эш көне эчендә кире кайтара;

7.1.2. электрон аукционда катнашу өчен түләү сыйфатында –ЭМ оператор тарафыннан дифференциацияләп билгеләнгән күләмдә, лотның башлангыч (минималь) бәясенә карап һәм электрон аукцион үткәрү турында мәгълүмати хәбәрдә күрсәтелгән күләмдә.

7.2. Электрон аукцион адымы лотның башлангыч (минималь) бәясенең биш проценты күләмендә билгеләнә.

## VIII. Электрон аукцион үткәрү турында мәгълүмати хәбәр һәм аукцион документациясе

8.1. Вәкаләтле орган электрон мәйданчыкта һәм Вәкаләтле орган сайтында электрон аукцион турында мәгълүмати хәбәр һәм аукцион документациясен бастырып чыгаруны гамәлгә ашыра.

8.2.Электрон аукцион уздыру турында мәгълүмати хәбәр Вәкаләтле орган тарафыннан электрон мәйданчыкта электрон аукционда катнашуга заявкалар бирү тәмамланганчы кимендә 30 (утыз) календарь көн кала урнаштырыла.

8.3. Аукцион документациясе үз эченә түбәндәге мәгълүматны алырга тиеш:

8.3.1. Вәкаләтле органның исеме, урнашкан урыны һәм элемтә өчен телефон номеры;

8.3.2. мөрәҗәгать итүчеләргә карата таләпләр;

8.3.3. объектның төре һәм мәйданы, аны урнаштыру урыны һәм срогы, профиле, лотның башлангыч (минималь) бәясе турындагы мәгълүматны үз эченә алган лот (лотлар) турында белешмәләр;

8.3.4. НТО проектына таләпләр яки күчмә корылмаларга таләпләр булганда;

8.3.5.заявканың эчтәлегенә, формасына, рәсмиләштерүенә һәм составына карата таләпләр;

8.3.6. заявканы тәэмин итү күләме, аны кертү срогы һәм тәртибе;

8.3.7. заявкаларны кабул итә башлау һәм тәмамлану датасын һәм вакытын;

8.3.8. заявкаларны карау датасы һәм вакыты;

8.3.9. заявкаларны кире алу тәртибе һәм срогы;

8.3.10. электрон аукцион уздыру датасы, вакыты һәм тәртибе;

8.3.11. аукцион документациясе белән танышу тәртибе;

8.3.12. электрон аукцион уздырганнан соң шартнамә төзү срогы;

8.3.13. НТО урнаштыруга хокук сату-алу шартнамәсенең проекты.

8.4. Вәкаләтле орган аукцион документациясенә үзгәрешләр кертү турында карар кабул итәргә хокуклы. Электрон аукцион предметын үзгәртү рөхсәт ителми. Вәкаләтле орган әлеге үзгәрешләрне электрон мәйданчыкта һәм Вәкаләтле орган

сайтында мондый карар кабул ителгән көннән алып бер көн эчендә, әмма заявкалар кабул итү тәмамланган көнгә кадәр бер эш көненнән дә соңга калмыйча урнаштыра.

8.5. Вәкаләтле орган электрон аукцион үткәрүдән баш тарту турында карар кабул итәргә хокуклы. Вәкаләтле орган электрон аукцион үткәрүдән баш тарту турында хәбәрнамәне электрон мәйданчыкта һәм Вәкаләтле органның рәсми сайтында мондый карар кабул ителгәннән соң бер көн эчендә, әмма аны үткәрү датасы башланырга өч көннән дә соңга калмыйча урнаштыра.

## IX. Электрон аукционда катнашу өчен заявкалар кабул итү тәртибе

9.1. Заявкаларны тапшыру бары тик электрон мәйданчыкта аккредитация алган затлар тарафыннан гына башкарыла. Электрон аукционда катнашу мөрәҗәгать итүченең электрон аукционнарда катнашуны тәэмин итү буенча операцияләр үткәрү өчен ачык счетында үзе биргән заявкаларны тәэмин итү өчен җитәрлек акчалары булганда гына мөмкин.

9.2. Заявка мөрәҗәгать итүче тарафыннан ике өлештә һәм заявка бирелә торган һәр лотка карата аукцион документациясе белән билгеләнгән форма буенча һәм срокларда тапшырыла. Заявканың һәр өлеше электрон цифрлы имза белән имзалана, заявканың ике өлеше дә бер үк вакытта тапшырыла.

9.3. Заявканың беренче өлеше түбәндәгеләрне үз эченә алырга тиеш:

9.3.1. аукцион документациясе нигезендә Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә НТО урнаштыруга хокук сатып алу буенча ризалыгы;

9.3.2. электрон аукцион үткәрү датасы һәм электрон аукцион номеры турында мәгълүмат.

9.4.Заявканың икенче өлеше түбәндәгеләрне үз эченә алырга тиеш:

9.4.1. юридик затның исеме һәм урнашу урыны йә «һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы индивидуаль эшкуарның, физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) һәм яшәү урыны, почта адресы, ИНН, гаризаны тәэмин итүне һәм (яисә) шартнамә төзүне кире кайтару өчен банк реквизитлары, контакт телефоны номеры; кече һәм урта эшкуарлык субъектлары арасында электрон аукцион уздырганда - мөрәҗәгать итүченең күрсәтелгән категориягә каравын раслый торган белешмәләр;

9.4.2. НТО урнаштырганда аукцион документларында күрсәтелгән шартларны үтәүгә ризалыгы;

9.4.3. электрон аукцион уздыру турында мәгълүмати хәбәрнамәне Вәкаләтле орган сайтында урнаштыру датасына кадәр кимендә алты ай кала алынган ЕГРЮЛдан өземтә күчермәсе;электрон аукцион уздыру турында мәгълүмати хәбәрнамәне Вәкаләтле орган сайтында урнаштыру датасына кадәр кимендә алты ай кала алынган ЕГРИПтан өземтә күчермәсе; электрон аукцион уздыру турында мәгълүмати хәбәрнамәне Вәкаләтле орган сайтында урнаштыру датасына кадәр кимендә алты ай кала тиешле дәүләт законнары нигезендә (чит ил затлары өчен) юридик затны яисә индивидуаль эшкуар буларак физик затны дәүләт теркәвенә алу турындагы документларның рус теленә тәрҗемә ителгән күчермәләре;

9.4.4. мөрәҗәгать итүче-юридик зат исеменнән затның гамәлләрне башкару вәкаләтләрен раслый торган документның күчермәсе (физик затны ышанычнамәсез катнашучы исеменнән эш итү хокукына ия булган вазыйфага билгеләү яисә сайлау турындагы карарның йә билгеләп кую турындагы боерыкның күчермәсе (алга таба - җитәкче)). Әгәр катнашучы исеменнән башка зат эш итсә, гаризада шулай ук мөрәҗәгать итүче исеменнән гамәлләрне башкаруга ышанычнамәнең мөрәҗәгать итүче мөһере белән таныкланган һәм мөрәҗәгать итүче җитәкчесе (юридик затлар

өчен) яисә әлеге җитәкче вәкаләт биргән зат тарафыннан имзаланган күчермәсе булырга тиеш.Әгәр күрсәтелгән ышанычнамә мөрәҗәгать итүченең вәкаләтле җитәкчесе тарафыннан имзаланган булса, гаризада шулай ук мондый затның вәкаләтләрен раслый торган документның күчермәсе булырга тиеш;

9.4.5. мөрәҗәгать итүченең гамәлгә кую документлары күчермәләре (юридик затлар өчен);

9.4.6. мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклаучы документның күчермәсен («Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы индивидуаль эшкуарлар, физик затлар өчен);

9.4.7. КНД 1122035 формасы буенча һөнәри керемгә салым түләүче сыйфатында физик затны исәпкә кую (исәптән төшерү) турындагы белешмәнең күчермәсен («Һөнәри керемгә салым махсус салым» режимын кулланучы физик затлар өчен);

9.4.8. мөрәҗәгать итүче - юридик затны ликвидацияләү турында карарның булмавы хакында, мөрәҗәгать итүчене - юридик затны, индивидуаль эшкуарны, «һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затны банкрот дип тану һәм конкурс производствосын ачу турында арбитраж суды карарының булмавы хакында, Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексында каралган тәртиптә мөрәҗәгать итүченең эшчәнлеген туктатып тору турында карарлар булмау хакында гариза

9.5.Заявка керү заявканы тәэмин итү күләмендәге акчаларга карата мөрәҗәгать итүченең электрон аукционда катнашуны тәэмин итү буенча операцияләр үткәрү өчен ачык булган счеты буенча операцияләрне туктату турында йөкләмә булып тора.

9.6. Мөрәҗәгать итүче һәр лотка карата бер генә заявка бирергә хокуклы.

9.7. ЭМ операторы заявканы түбәндәге очракларда кабул итүдән баш тарта:

9.7.1. электрон документлар әйләнеше турындагы таләпләрне бозып заявка бирү;

9.7.2. заявка биргән мөрәҗәгать итүченең электрон аукционнарда катнашуны тәэмин итү буенча операцияләр үткәрү өчен ачык счетында заявканы тәэмин итү күләмендә акчалар булмау;

9.7.3. мөрәҗәгать итүче тарафыннан элек бирелгән заявкалар кире алынмаган очракта бер мөрәҗәгать итүченең бер үк лотка карата ике һәм аннан да күбрәк гариза бирүе . Бу очракта мөрәҗәгать итүчегә әлеге лотка карата бирелгән барлык заявка лар кире кайтарыла;

9.7.4. заявкалар бирү срогы тәмамланганнан соң заявка алыну;

9.7.5. аккредитация кагыйдәләрен бозып заявка алыну.

Мөрәҗәгать итүчегә электрон аукционда катнашудан баш тарту өчен күрсәтелгән нигезләр исемлеге тулы була.

9.8. Мөрәҗәгать итүче заявкасын заявкаларны кабул итү тәмамланганчы теләсә кайсы вакытта кире алырга хокуклы.

9.9. Заявка бирү электрон аукционда катнашучы электрон аукцион йомгаклары буенча җиңүче дип танылган һәм аңа шартнамә төзү хокукы бирелгән очракта, электрон аукционда катнашуны тәэмин итү буенча операцияләр үткәрү өчен ачык булган счеттагы акчаларны электрон аукционда катнашкан өчен түләү сыйфатында тотуга мөрәҗәгать итүченең ризалыгы булып тора.

9.10.ЭМ операторы заявкаларның икенче өлешләрен Вәкаләтле орган адресына карауга җибәргәнчегә кадәр үзара хезмәттәшлекнең барлык якларына карата заявкалар биргән мөрәҗәгать итүчеләр турында белешмәләрнең конфиденциальлеген тәэмин итә.

9.11. Аукционда катнашуга заявкалар бирү срогы тәмамланган вакытка бер генә заявка бирелгән яисә бер заявка да бирелмәгән очракта, аукцион узмаган дип таныла.

9.12. Электрон аукционның заявкалар реестрында заявкалар бирү, кире алу һәм кире кайтару нәтиҗәләре буенча бер заявка булса, заявканың беренче өлеше турындагы белешмәләр белән бер үк вакытта заявканың икенче өлеше карауга җибәрелә.

## X. Заявкаларның беренче өлешләрен карап тикшерү тәртибе

10.1. Комиссия заявкаларның беренче өлешләрен тикшерә, мондый тикшерү вакыты заявкалар бирү срогы тәмамланганнан соң биш эш көненнән артып китә алмый.

10.2. Заявкаларның беренче өлешләрен карап тикшерү тәмамланганнан соң Комиссия заявкаларның беренче өлешләрен карап тикшерүнең язма беркетмәсен төзи, аңа Комиссиянең утырышта булган барлык әгъзалары имза сала. Күрсәтелгән беркетмә һәр заявка буенча рөхсәт итү йә рөхсәт итүдән баш тарту турында карарларны үз эченә ала, беркетмәгә имза салынган көннең иртәгесеннән дә соңга калмыйча ЭМ операторына җибәрелә һәм электрон мәйданчыкта бастырып чыгарыла.

10.3. ЭМ операторы тарафыннан заявкаларны карап тикшерү беркетмәсе электрон мәйданчыкта бастырылганнан соң бер сәгать эчендә барлык мөрәҗәгать итүчеләргә заявкаларына карата кабул ителгән карарлар турында хәбәрнамәләр җибәрелә.

10.4. Электрон аукцион түбәндәге очракларда уздырылмаган дип таныла:

10.4.1. Заявкалар бирү срогы тәмамланганда бер генә заявка бирелү;

10.4.2. Заявкалар бирү срогы тәмамланганда бер генә заявка да бирелмәү;

10.4.3. Комиссия тарафыннан барлык мөрәҗәгать итүчеләргә карата электрон аукционда катнашуга рөхсәт бирүдән баш тарту турында карар кабул ителү.

Әгәр аукцион документациясе белән ике лот һәм аннан да күбрәк каралган булса, электрон аукцион мондый карар кабул ителгән лотлар буенча узмаган дип таныла.

10.5. Электрон аукцион әлеге Нигезләмәнең 10.4.2 пунктчасында күрсәтелгән сәбәпләр буенча үткәрелмәгән дип танылган очракта, Вәкаләтле орган яңа электрон аукцион уздыру турында игълан итәргә хокуклы. Яңа электрон аукцион уздыру турында игълан ителгән очракта Вәкаләтле орган аның шартларын үзгәртергә хокуклы.

10.6. Комиссия тарафыннан заявкаларның беренче өлешләрен карап тикшерү турында беркетмә рәсмиләштерелгән моменттан мөрәҗәгать итүче электрон аукционда катнашучы статусын ала.

## XI. Электрон аукционны оештыру һәм уздыру

11.1. Электрон аукцион электрон мәйданчыкта мәгълүмати хәбәрдә күрсәтелгән көнне үткәрелә. Электрон аукцион үткәрү вакыты Мәскәү вакыты буенча ЭМ операторы тарафыннан билгеләнә.

11.2. Электрон аукцион уздырыла башлаган вакыттан катнашучы лот бәясе турында үз тәкъдимнәрен бирергә хокуклы.

11.3. Электрон мәйданчыкта аукцион адымы лотның башлангыч (минималь) бәясенең биш процентын тәшкил итә.

11.4. Электрон аукцион уздыру вакытында катнашучы тарафыннан бирелгән лот бәясе турындагы һәр тәкъдим электрон цифрлы имза белән имзалана.

11.5.Электрон аукцион уздырганда лот бәясе турындагы тәкъдим тиененә кадәр төгәллек белән теркәлә.

11.6. Электрон аукционда катнашучылар агымдагы максималь тәкъдимне аукцион адымы чикләрендә күтәрүне күздә тоткан лот бәясе турында тәкъдимнәр бирәләр.

11.7. Аукцион җиңүчесе итеп лотның иң югары бәясен тәкъдим иткән катнашучы танына.

11.8. Соңгы тәкъдимне кабул иткәннән соң яки электрон аукцион башланганнан соң ун минут эчендә лот бәясе турында бер генә тәкъдим дә бирелмәгән очракта, әлеге лот буенча электрон аукцион автомат рәвештә төгәлләнә.

11.9. Электрон аукцион уздыру протоколы ЭМ операторы тарафыннан электрон мәйданчыкта электрон аукцион тәмамланганнан соң 30 (утыз) минут эчендә урнаштырыла.

11.10.Электрон аукцион уздыру беркетмәсендә электрон мәйданчыкның адресы; электрон аукционның башлану һәм тәмамлану датасы; лотның башлангыч (минималь) бәясе; лот бәясе турында тиешле тәкъдимнәр ясаган электрон аукционда катнашучылар тарафыннан әлеге тәкъдимнәрнең килү вакытын , электрон аукционда катнашуга заявкалар бирелгән тәртип номерларын күрсәтеп, электрон аукционда катнашучылар тарафыннан ясалган һәм түбәнәю барган саен ранжировкаланган лот бәясе турындагы бирелгән барлык максималь тәкъдимнәр күрсәтелә.

11.11. Әгәр электрон аукцион уздыру башланганнан соң ун минут эчендә электрон аукционда катнашучыларның берсе дә лот бәясе турында тәкъдим бирмәгән булса, электрон аукцион булмаган дип танына. Күрсәтелгән вакыт тәмамланганнан соң утыз минут эчендә ЭМ операторы электрон мәйданчыкта электрон аукционны булмаган дип тану турында беркетмә урнаштыра (электрон мәйданчыкның адресын, датасын, электрон аукционның башлану һәм тәмамлану вакытын, лотның бәясен күрсәтеп) һәм аны Вәкаләтле органга җибәрә.

## XII.Электрон аукционда катнашуга заявкаларның икенче өлешләрен карап тикшерү һәм нәтиҗә ясау

12.1.Электрон аукцион үткәрү беркетмәсен электрон мәйданчыкта урнаштырганнан соң бер сәгать эчендә ЭМ операторы Вәкаләтле органга электрон аукцион уздыру беркетмәсен, электрон аукционда катнашучылар биргән электрон аукционда катнашуга заявкаларның икенче өлешләрен һәм аккредитацияләнгән катнашучылар реестрыннан белешмәләрне җибәрә.

12.2. Комиссия электрон аукционда катнашуга гаризаларның икенче өлешләрен аукцион документациядә билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәвен карап тишерә.

12.3. Заявкаларның икенче өлешләрен карап тикшерүнең гомуми срогы, шулай ук аккредитацияләнгән катнашучылар реестрыннан белешмәләр электрон аукцион үткәрү беркетмәсе электрон мәйданчыкта урнаштырылган көннән алып өч эш көненнән артып китә алмый.

12.4. Комиссия заявкаларның икенче өлешләрен электрон аукционда катнашуга аукцион документациясендә каралган таләпләргә туры килү турында карар кабул ителгәнчегә кадәр карый. Заявкаларның икенче өлешләрен карау лотның иң югары бәясен тәкъдим иткән электрон аукционда катнашучы биргән заявкадан башлана һәм электрон аукционда катнашуга заявкалар ранжировкасын исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

12.5. Комиссия тарафыннан электрон аукционда катнашуга заявканың икедән бер өлеше генә аукционда каралган таләпләргә туры килүе турында карар кабул ителгән очракта, мондый катнашучы бердәнбер катнашучы дип таныла.

12.6.Әгәр Бердәм комиссия тарафыннан электрон аукцион турында документацияләр белән билгеләнгән таләпләргә анда катнашуга заявкаларның барлык икенче өлешләре туры килмәү хакында яки анда катнашуга заявкаларның икедән бер өлеше генә күрсәтелгән таләпләргә туры килүе турында карар кабул ителгән булса, мондый аукцион узмаган дип таныла.

12.7.Заявкаларның аукцион документациясендә билгеләнгән таләпләргә туры килү турында карар кабул ителгән очракта, шулай ук электрон аукционда катнашучыларның барысы тарафыннан да бирелгән гаризаларның икенче өлешләрен карап тикшерү нигезендә бердән күбрәк гаризаның күрсәтелгән таләпләргә туры килүе турында карар кабул ителгәндә, Комиссия тарафыннан электрон аукционга нәтиҗә ясау беркетмәсе рәсмиләштерелә, ул заявкаларны карап тикшерү тәмамланган көнне утырышта катнашкан барлык Комиссия әгъзалары тарафыннан имзалана.

12.8. Беркетмәдә ранжирланган һәм аларга карата аукцион документациясе белән билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында карар кабул ителгән электрон аукционда катнашуга заявкаларның тәртип номерлары турында һәм электрон аукционда катнашуга гаризаларының икенче өлешләре карап тикшерелгән катнашучылар турында белешмәләр, кабул ителгән карарга нигезләнеп, электрон аукционда катнашуга заявкаларның аукцион документациясе белән билгеләнгән таләпләргә туры килүе яисә туры килмәве турында кабул ителгән карар, заявканың аукцион документациясе белән билгеләнгән таләпләргә туры килүе яисә туры килмәве турында Комиссиянең һәр әгъзасы карары хакында белешмәләр булырга тиеш.

12.9. Лотның иң югары бәясен тәкъдим иткән һәм заявкасы аукцион документациясе таләпләренә туры килгән электрон аукционда катнашучы электрон аукцион җиңүчесе дип таныла.

12.10. НТО урнаштыруга хокук сату-алу шартнамәсен төзү хокукы күрсәтелгән заявка аукцион документациясендә каралган таләпләргә һәм шартларга туры килсә, бердәнбер заявка биргән затка, шулай ук аукцион документациясендә каралган шартларда электрон аукционның бердәнбер катнашучысы дип танылган затка электрон аукцион үткәрү турында мәгълүмати хәбәрләмәдә күрсәтелгән лотның башлангыч (минималь) бәясенә тигез бәя белән торглар үткәрмичә тапшырылырга мөмкин.

## XIII. Заявканы тәэмин итүне кире кайтару тәртибе

13.1. Мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан заявканы тәэмин итү сыйфатында кертелгән акчалата чаралар ЭМ операторы тарафыннан биш эш көне эчендә кире кайтарыла:

13.1.1. мөрәҗәгать итүчеләргә - электрон аукцион уздырудан баш тарту турында хәбәр электрон мәйданчыкта урнаштырылган көннән;

13.1.2. мөрәҗәгать итүчегә заявканы кире алуга бәйле рәвештә - заявкаларны кабул итү тәмамланган көнгә кадәр;

13.1.3. электрон аукцион узмаган дип танылган очракта мөрәҗәгать итүчеләргә - заявкаларның беренче өлешләрен карау беркетмәсен электрон мәйданчыкта урнаштырган көннән;

13.1.4. электрон аукционда катнашучыларга - электрон аукционга йомгак ясау беркетмәсе электрон мәйданчыкта урнаштырылган көннән башлап, җиңүчедән һәм электрон аукционда җиңүче тәкъдим иткән лот бәясеннән соң килә торган лотның иң

югары бәясен тәкъдим иткән башка катнашучыдан тыш (алга таба-икенче катнашучы);

13.1.5. икенче катнашучыга - җиңүче белән шартнамә төзелгәннән соң.

13.2. Электрон аукцион җиңүчесе дип танылган яисә икенче катнашучы шартнамә төзүдән баш тарткан очракта, әлеге Нигезләмәнең 7.1.1 пунктчасы нигезендә мондый катнашучылар тарафыннан заявкалар тәэмин итү сыйфатында кертелгән акчалар кире кайтарылмый, ә ЭМ операторы тарафыннан Вәкаләтле орган хисабына күчерелә.

## XIV. Аукцион уздыру нәтиҗәләре буенча шартнамә төзү

14.1. Шартнамә түбәндәгеләр белән төзелә:

14.1.1. электрон аукцион җиңүчесе белән;

14.1.2. аукцион җиңүчесе билгеләнгән срокта шартнамә төзүне кире какканда яисә төзүдән баш тартканда - икенче катнашучы белән;

14.1.3. Комиссия тарафыннан заявкасы һәм документлары аукцион окументациясенә туры килә дип танылган очракта, бердәнбер заявка бирүче белән.

14.1.4. заявкаларның икенче өлешләрен карап тикшерү нәтиҗәләре буенча Комиссия тарафыннан бердәнбер катнашучы дип танылган электрон аукционда катнашучы белән.

14.2. Вәкаләтле орган тарафыннан шартнамә төзү Россия Федерациясе Граждан кодексы һәм башка федераль законнар белән каралган тәртиптә башкарыла.

14.3.Шартнамә электрон аукционда җиңүче игълан ителгән көннән алып 20 (егерме) эш көненнән дә соңга калмыйча төзелә.

Электрон аукцион нәтиҗәләрен ясау беркетмәсендә күрсәтелгән урында законсыз урнаштырылган НТО ачыкланган очракта, Вәкаләтле орган әлеге объектны демонтажлау буенча эш алып бара, шул ук вакытта НТО урнаштыруга шартнамә аукцион җиңүчесе игълан ителгәннән соң 60 календарь көннән дә соңга калмыйча төзелә.

14.4. Вәкаләтле орган электрон аукционга йомгак ясау беркетмәсе электрон мәйданчыкта урнаштырылган көннән алып биш эш көне эчендә электрон аукционда катнашучы тарафыннан тәкъдим ителгән лотның йомгаклау бәясен кертү юлы белән төзелгән шартнамә проектын ЭМ операторына җибәрә. ЭМ операторы бер сәгать эчендә килгән шартнамә проектын электрон аукцион җиңүчесенә җибәрә.

14.5. Электрон аукционда җиңүче шартнамә проектын алганнан соң биш эш көне эчендә электрон мәйданчыкларның эшләү шартларына туры китереп, электрон аукционда катнашучы исеменнән эш итәргә хокуклы затның көчәйтелгән электрон имзасы белән имзаланган шартнамә проектын ЭМ операторына җибәрә. ЭМ операторы электрон аукцион җиңүчесеннән кергән шартнамәне бер сәгать эчендә Вәкаләтле орган адресына җибәрә.

14.6. Электрон аукционда җиңүче, Нигезләмәнең 14.5 пунктында каралган срокта, электрон мәйданчыкларның эш итү шартларына туры китереп, электрон аукционда катнашучы исеменнән эш итәргә хокукы булган затның көчәйтелгән электрон имзасы белән имзаланган шартнамә проектын Вәкаләтле органга җибәрмәгән очракта, шартнамә төзүне кире каккан дип таныла.

14.7.Нигезләмәнең 14.6 пунктында күрсәтелгән очракта, җиңүче шартнамә төзүне кире каккан дип танылганнан соң, икенче катнашучыга имзалау өчен Вәкаләтле орган өч эш көне эчендә ЭМ операторына шартнамә проектын җибәрә.

14.8. Шартнамә проектын алганнан соң биш эш көне эчендә электрон мәйданчыкларның эшләү шартларына туры китереп икенче катнашучы электрон аукционда катнашучы исеменнән эш итәргә хокуклы затның көчәйтелгән электрон

имзасы белән имзаланган шартнамә проектын ЭМ операторына җибәрә. ЭМ операторы икенче катнашучыдан кергән шартнамәне Вәкаләтле орган адресына бер сәгать эчендә җибәрә.

14.9.Әлеге Нигезләмәнең 14.6 пунктчасында күрсәтелгән очракта, электрон аукцион җиңүчесе шартнамә төзү хокукын югалта һәм заявканы тәэмин итү буенча акча аңа кире кайтарылмый, ә ЭМ операторы тарафыннан Вәкаләтле орган счетына күчерелергә тиеш.

14.10. Икенче катнашучы шартнамә проектын имзалаудан баш тарткан очракта, ул шартнамә төзү хокукын югалта һәм заявканы тәэмин итү аңа кире кайтарылмый, ә ЭМ операторы тарафыннан Вәкаләтле орган счетына күчерелергә тиеш.

14.11.Нигезләмәнең 14.1.1, 14.1.2 пунктчаларында күрсәтелгән затлар лот буенча шартнамә төзүне кире каккан очракта, әлеге лот буенча электрон аукцион узмаган дип таныла һәм Вәкаләтле орган лотны торгка кабат куярга хокуклы.

14.12. Аукцион җиңүчесе яки икенче катнашучы шартнамә төзүне кире каккан очракта, Вәкаләтле орган мондый катнашучыларны шартнамә төзергә мәҗбүр итү һәм шартнамә төзүне кире кагу нәтиҗәсендә китерелгән зыянны каплау өчен иск белән судка мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2026 елның 20 гыйнварындагы
83 номерлы карарына
2 нче кушымта

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ «ЗЕЛЕНОДОЛЬСК ШӘҺӘРЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ ТЕРРИТОРИЯСЕНДӘ СТАЦИОНАР БУЛМАГАН СӘҮДӘ ОБЪЕКТЛАРЫН УРНАШТЫРУГА ХОКУК САТУ БУЕНЧА ЭЛЕКТРОН АУКЦИОН ҮТКӘРҮ КОМИССИЯСЕ
СОСТАВЫ

| Вазифасы | Ф.И.Ат.и. |
|---|---|
| Рәис – Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары | А.С. Бауэр |
